КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

23.04.2018 №4

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ”Актаныш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси хуҗалыкларда йөреп чыгу турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык буенча исәпкә алуны алып бару максатларында, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан хуҗалык кенәгәләрен алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында»2010 елның 11 октябрендәге 345 номерлы Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән, Актаныш авыл башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш авыл җирлеге территориясендә шәхси йортларның ишегалларында йөреп чыгуны үткәрү өчен эшче төркеме төзергә һәм аның составын (1-нче кушымта) һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны йөреп чыгу графигын расларга (2-нче кушымта).
2. Эшче төркемгә 2018 елның 1 маена кадәр шәхси ярдәмче хуҗалык турында гражданнар биргән белешмәләрнең дөреслеген билгеләү яки әлеге мәгълүматны яшереп калдыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы терлекләрнең санын ачыклау максатында, җирлек территориясендә хуҗалыкларны йөреп чыгарга.
3. Электрон хуҗалык кенәгәләрен алып бару, аларга билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү һәм аларның сакланышын Актаныш авыл башкарма комитетының әйдәп баручы белгечләреннән И.Н. Бакированы һәм Р.Б.Мәрдәнованы билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының «Актаныш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә игълан итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М.Сергеевага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Шәрәпов

Актаныш авыл җирлеге территориясендә
хуҗалыкларга йөреп чыгу буенча эшче төркеме
составы

1. Бакирова И.Н.-Актаныш авыл башкарма комитетының әйдәп баручы белгече;
2. Мәрдәнова Р.Б.- Актаныш авыл башкарма комитетының әйдәп баручы белгече;
3. Загертдинов И.Р.-ветеринар-фельдшер «Актаныш РДВБ» ДБУ (килешү буенча);
4. Әгъләмов Л.А.-ветеринар-табиб «Актаныш РДВБ» ДБУ (килешү буенча);
5. Индаев Н.К.«Актаныш РДВБ» ДБУ ветеринария-фельдшеры (килешү буенча);
6. Солтанов Р.А.-Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча вәкаләтле вәкиле, полиция капитаны (килешү буенча);
7. Фазлыев Д.Д. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча участок уполномоченные, кече полиция лейтенанты (килешү буенча).

Актаныш авыл җирлеге территориясендә урнашкан шәхси
ярдәмче хуҗалыкларны йөреп чыгу графигы

2018 елның 23 апрелендә җирлекнең РТСта һәм 57 нче кварталында урнашкан хуҗалыклар;
2018 елның 25 апреле - Түбән Актаныш бистәсендә урнашкан хуҗалыклар., Актаныш р.ү.